РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН

**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ ЮТАЗИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА**

423950, п.г.т. Уруссу, ул. Пушкина, д.38
тел.: (85593) 2-74-16, факс: (85593) 2-62-20

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ

**ЮТАЗЫ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

423950, Урыссу ш.т.б., Пушкин урамы, 38
тел.: (85593) 2-74-16, факс: (85593) 2-62-20


**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

« 29 » 07 2021 ел № 589

Хезмәтне саклау буенча Координация Советы турында

Хезмәтне саклау өлкәсендә гражданнарның хокукларын гамәлгә ашыру максатларында һәм Россия Федерациясе Хезмәт кодексы (210 ст.), "Татарстан Республикасында хезмәтне саклау турында" Татарстан Республикасы Законы, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының "Татарстан Республикасында хезмәтне саклау өлкәсендә дәүләт сәясәтен гамәлгә ашыру турында" 2008 елның 10 октябрендәге 799 номерлы карары нигезендә, Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы карар бирә:

1. Расларга:

1.1.Яңа составта Хезмәтне саклау буенча Координация Советын (1 нче кушымта);

1.2.Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы башкарма комитеты каршындагы Хезмәтне саклау буенча координация советы турында Нигезләмәне (2 нче кушымта).

2. Ютазы муниципаль районы Башкарма комитетының «Хезмәтне саклау буенча Координацион советның район ведомствоара комиссиясен төзү турында» 01.02.2016 ел, №51 карарын үз көчен югалткан дип танырга;

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының «Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре Порталында Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә http://jutaza.tatarstan.ru адресы буенча Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Башкарма комитет җитәкчесе С. П. Самонина

Г.Г. Исмәгыйлева
2-74-97

1 нче кушымта
Ютазы муниципаль
районы Башкарма
комитеты
карарына
«__»______2021 ел
№__

Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Башкарма комитеты каршындагы Хезмәтне саклау буенча Координация Советы турында

1. Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Башкарма комитеты каршындагы Хезмәтне саклау буенча Координация Советы (алга таба - Совет) Ютазы муниципаль районында хезмәтне саклау өлкәсендә дәүләт сәясәтен гамәлгә ашыру максатларында төзелә.

2. Совет җирле үзидарә органнарының эш бирүчеләр, оешмаларның хезмәтне саклау хезмәтләре, хезмәтне саклау, күзәтчелек һәм контроль өлкәсендә дәүләт идарәсе органнары, социаль иминият фонды һәм башка иҗтимагый оешмалар белән үзара хезмәттәшлегендә үз эшчәнлеген гамәлгә ашыра.

3. Совет үз эшчәнлегендә Россия Федерациясе Конституциясенә, Татарстан Республикасы Конституциясенә, Россия Федерациясенең һәм Татарстан Республикасының хезмәтне саклау өлкәсендәге закон чыгару һәм башка норматив-хокукый актларына, шулай ук әлеге Типовой нигезләмәгә таяна.

4. Советның төп бурычлары түбәндәгеләр:

хезмәтне саклау өлкәсендә дәүләт сәясәтен гамәлгә ашыру эшчәнлеген координацияләү;

эш бирүчеләрнең хезмәтне саклау таләпләрен үтәүләрен тикшереп тору;

эш урыннарында хезмәткәрләрнең куркынычсыз шартларга һәм хезмәтне саклауга хокукларын яклау;

төрле милек рәвешләрендәге оешмаларда хезмәт шартларының торышын һәм хезмәтне саклауның торышын анализлау һәм аларны яхшырту буенча чаралар күрү;

хезмәт шартларын яхшырту һәм хезмәтне саклау буенча территориаль программалар эшләү һәм кабул итү;

оешма җитәкчеләре һәм белгечләре, хезмәтне саклау өлкәсендә хезмәт күрсәтүче башкарма хакимият органнары,

оешмалар һәм лабораторияләр, фәнни оешмалар, медицина учреждениеләре, хезмәтне саклау буенча уку үзәкләре вәкилләре катнашында семинарлар, киңәшмәләр, "түгәрәк өстәлләр", "хезмәтне саклау көннәре", шулай ук хезмәтне саклау буенча башка чаралар үткәрү;

барлык оештыру-хокукый рәвешләрендәге һәм милек рәвешләрендәге оешмалар арасында хезмәтне саклау һәм аның шартлары буенча иң яхшы эшләрне оештыруга смотр-конкурслар үткәрү.

5. Совет үзенә йөкләнгән бурычлар нигезендә:

хезмәтне саклау турында гамәлдәге законнарны гамәлгә ашыруга бәйле мәсьәләләрне карый;

хезмәт шартларын яхшырту һәм хезмәтне саклау буенча территориаль программалар эшләү өчен эшче төркемнәр төзи;

хезмәт шартларын яхшыртуның һәм хезмәтне саклауның территориаль программаларын гамәлгә ашыруны тикшереп тора;

шартларның һәм хезмәтне саклауның торышын өйрәнү һәм анализлау һәм аларны яхшырту буенча чаралар күрү максатларында, Совет әгъзаларының төрле милек рәвешләрендәге оешмаларда булуын планлаштыра;

эш бирүчеләр тарафыннан хезмәткәрләргә авыр эш, зарарлы һәм (яисә) куркыныч хезмәт шартлары өчен компенсацияләр, шул исәптән сөт яисә башка аның белән бер кыйммәтәге азык-төлек продуктлары бирүнең дөреслеге мәсьәләләрен карый;

хезмәтне саклау һәм хезмәт шартлары эшләрен иң яхшы оештыруга смотр-конкурсларда барлык оештыру-хокукый рәвешләрдәге һәм милек рәвешендәге оешмаларның катнашуын оештыра;

барлык оештыру-хокукый рәвешендәге һәм милек рәвешендәге оешмалар арасында хезмәтне саклау һәм аның шартлары эшләрен иң яхшы оештыруга смотр-конкурсларда җиңүчеләрне билгели;

хезмәтне саклау һәм производство санитариясе өлкәсендә профилактик эшнең алдынгы ысулларын һәм рәвешләрен кертү мәсьәләләре буенча оешмаларга ярдәм итә;

50 дән артык хезмәткәре булган оешмаларда хезмәтне саклау хезмәтләрен булдыруга ярдәм итә;

төркем бәхетсезлек очракларының сәбәпләрен, үлемгә китергән бәхетсезлек очракларын һәм аларны бетерү буенча күрелә торган чараларны тикшерә;

җитештерү травматизмының, аварияләрнең һәм һөнәри авыруларның үсешен булдырган яисә югары дәрәҗәдә булган оешмаларда күзәтчелек һәм контроль органнары үткәргән тикшерүләр нәтиҗәләрен карый;

хезмәт шартлары буенча эш урыннарына аттестация, аннары барлык милек рәвешләрендәге оешмаларда хезмәтне саклау эшләрен сертификацияләү уздыруны активлаштыруга ярдәм итә;

үз утырышларында эш бирүчеләрнең эш урыннарында производство травматизмын һәм һөнәри авыруларны кисәтү, хезмәт шартларын яхшырту һәм хезмәтне саклау буенча күрелә торган чаралары турында тыңлый;

Татарстан Республикасында дәүләт хезмәт инспекциясе, прокуратура, Татарстан Республикасы буенча Роспотребнадзор органнарына, күзәтчелек һәм контрольнең башка органнарына, хезмәтне саклау турындагы законнар таләпләрен бозуга юл куйган эш бирүчеләргә карата җитештерү травматизмы һәм һөнәри авыру дәрәҗәсенең югары булуы сәбәпле чаралар күрү турында тәкъдимнәр кертә;

Ютазы муниципаль районы башкарма комитеты җитәкчесенә зарарсыз технологияләр һәм җитештерү чараларын гамәлгә кертүче эш урыннарында хезмәт шартларын яхшырту һәм хезмәтне саклау буенча уңай тәҗрибәгә ия эш бирүчеләрне бүләкләү турында тәкъдимнәр кертә;

оешмаларда хезмәтне саклау буенча күмәк шартнамәләр һәм килешүләр төзү, хезмәтне саклау буенча җитәкчеләрне һәм белгечләрне укыту, махсус кием, махсус аяк киеме һәм башка индивидуаль саклану чаралары белән эшләүчеләрне тәэмин итү эшләренең агымдагы торышын карый;

хезмәт шартларын яхшырту һәм хезмәтне саклау буенча үзебезнең илдәге һәм чит илләр алдынгы эш тәҗрибәләрен таратуга ярдәм итә.

6. Ютазы муниципаль районы башкарма комитеты җитәкчесенең урынбасарларыннан берсе Совет рәисе була ала;

7. Совет составы Ютазы муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе карары белән раслана. Совет составына җирле үзидарә органнары вәкилләре, төрле милек рәвешләрендәге оешмалар җитәкчеләре һәм белгечләре, Татарстан Республикасында дәүләт хезмәт инспекциясе, Татарстан Республикасы буенча Роспотребнадзор, социаль иминият фондының җирле органнары, профсоюзлар һәм башка иҗтимагый оешмалар вәкилләре (килешү буенча) керергә мөмкин.

8. Координация Советы үз эшчәнлеген Ютазы муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе тарафыннан раслана торган эш планы нигезендә гамәлгә ашыра.

9. Координация Советы утырышы, әгәр анда аның әгъзаларының яртысыннан күбрәге катнашса, тулы хокуклы дип санала.

10. Координация Советы утырышлары кварталга кимендә 1 тапкыр уздырыла.

11. Совет карарлары ачык тавыш бирү юлы белән кабул ителә һәм, әгәр алар өчен утырышта катнашучыларның яртысыннан артыгы тавыш бирсә, кабул ителгән дип санала. Тавышлар тигез булган очракта, рәис тавышы хәлиткеч булып тора.

12. Совет утырышлары рәис һәм сәркатип тарафыннан имзалана торган беркетмәләр белән рәсмиләштерелә.

2 нче кушымта
Ютазы муниципаль районы
Башкарма комитеты карарына
«__»______2021 ел №__

Хезмәтне саклау буенча координация советы составы

| № т/б | Фамилиясе, исеме, атасының исеме | Биләнгән вазыйфасы |
|---|---|---|
| 1. | З.З. Гыйбадуллина | Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы башкарма комитеты җитәкчесенең беренче урынбасары, комиссия рәисе |
| 2. | Хәернасов Ф.Р. | Әлмәт шәһәрендәге бүлек начальнигы - баш дәүләт хезмәт инспекторы, рәис урынбасары (килешү буенча) |
| 3. | Исмәгыйлева Г.Г. | Ютазы муниципаль районы башкарма комитетының территориаль үсеш бүлеге башлыгы урынбасары, сәркатип |
| Комиссия әгъзалары | | |
| 4. | Борисов А. В. | Ютазы муниципаль районының Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек идарәсе начальнигы (килешү буенча) |
| 5. | Баһаутдинов К.Ф. | РФ Тикшерү комитетының ТР буенча тикшерү идарәсенең Азнакай районара тикшерү бүлеге җитәкчесе юстиция майоры (килешү буенча) |
| 6. | Вафина Г.А. | ТР буенча Роспотребнадзорның ТР буенча идарәсенең 1 нче разрядлы өлкән белгече Бөгелмә, Азнакай, Баулы районнарында (килешү буенча) |
| 7. | Габдрахманов И.Н. | Ютазы районы прокуроры урынбасары (килешү буенча) |
| 8. | Җәләев Д.Р. | РФ Социаль иминият фондының ТР буенча төбәк бүлеге |

| | | |
|---|---|---|
| | | дәүләт учреждениесенең иминият кертемнәре белән идарә итү бүлегенең баш белгече (10 нчы филиал), (килешү буенча) |
| 9. | Захаров А.Н. | Ютазы муниципаль районы башкарма комитетының инфраструктура үсеше бүлеге начальнигы |
| 10. | Муллагалиева Р.К. | Татарстан Республикасында Кеше хокуклары буенча вәкаләтле вәкилнең Ютазы муниципаль районында иҗтимагый ярдәмчесе (килешү буенча) |
| 11. | Миңнevәлиев Н.Н. | «Ютазы районы халыкны эш белән тәэмин итү үзәге» ДКУ директоры - рәис урынбасары (килешү буенча) |
| 12. | Солтанов Ф.Ф. | Татарстан Республикасы буенча Русия ГТХМ Баш идарәсенең 11 нче янгын-коткару бүлеге башлыгы (килешү буенча). |
| 13. | Саттаров В.С. | “Әпсәләм төзелеш конструкцияләре һәм материаллары комбинаты” ҖЧҖның хезмәтне саклау һәм сәнәгать куркынычсызлыгы буенча бүлеге начальнигы |
| 14. | Шакирова С.З. | Урыссу үзәк район хастаханәсенең баш табибы (килешү буенча) |